Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге
Иске Йорт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

16 октябрь, 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында 2024 елның 16 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 81 (сиксән бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 48 (кырык сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 36 (кырык алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 2 (ике).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча « Сез, 2025 елда Иске Йорт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнарны, студентларны бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, 1600 сум күләмендә үзара салым кертүгә, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов